**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «16» июненнән № 149

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 27 декабрендәге 614 номерлы «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында»**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы рекомендацияләре нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» гы 27.12.2018 ел, № 614 карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

"Гомуми нигезләмәләр» бүлегендәге 1.3.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт, шулай ук бүлекнең урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүматны алырга мөмкин:

1) Башкарма комитет биналарында урнашкан мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша.

Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында (http:// novosheshminsk.tatarstan.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugitatar.ru/) (алга таба - Региональ портал);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/) ((алга таба - Бердәм портал);

5) Башкарма комитетта (Бүлектә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә-шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада - электрон почта аша.»

«Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты"ның 2 бүлегендә «Стандарт таләпләре» баганасында:

2.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, гариза бирү көнен дә кертеп, биш көн.

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын бирү - өч көн.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торучы документны мөрәҗәгать итүчегә тапшыру мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документ гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла»

2.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

Рөхсәт алу өчен гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1) гариза:

- документ формасында кәгазьдә;

- Региональ портал аша мөрәҗәгать иткәндә, «Электрон имза турында» 06.04.2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада;

2) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар (төп нөсхәләр яки нотариаль тәртиптә расланган күчермәләр), шул исәптән сервитутны билгеләү турында килешү, әгәр аңа хокук Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса, гавами сервитутны билгеләү турында карар;

3) төзелешне башкаручы зат (төзелешне башкаручы зат, төзүче яисә техник заказчы тарафыннан, төзелеш подряды килешүе нигезендә төзелешне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру очрагында) тарафыннан имзаланган, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының урнашуын, җир кишәрлеге чикләрендә инженер-техник тәэмин итү челтәрләренең урнашуын һәм җир кишәрлеген планлаштыру схемасы (линияле объектны төзү, реконструкцияләү очракларыннан тыш);

4) Капиталь төзелеш объектын кабул итү акты (төзелеш, төзелеш подряд килешүе нигезендә төзелгән очракта).

5) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның таләпләренә туры килүен раслаучы һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан имзаланган документ.

6) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документациясе параметрларына туры килүен раслый торган һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат (төзүне гамәлгә ашыручы зат, төзүче, яисә төзелеш подряды килешүе нигезендә төзелеш, реконструкцияләүне гамәлгә ашырган очракта, техник заказчы, шулай ук килешү нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыру очрагында, төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат ), тарафыннан, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру очракларыннан тыш, кул куйган Акт.

7) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник шартларга туры килүен раслый торган һәм инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен

эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешма вәкилләре тарафыннан имзаланган документлар (алар булганда).

8) куркыныч объекттагы авария нәтиҗәсендә зыян күргән өчен куркыныч объект хуҗасының Россия Федерациясе законнары нигезендә куркыныч объекттагы авария нәтиҗәсендә зыян күргән өчен гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе төзүне раслаучы Документ.;

9) «Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» Федераль законның 41 статьясы таләпләренә туры китереп әзерләнгән техник план.

10) мәдәни мирас объектын реставрацияләү, консервацияләү, ремонтлау һәм заманча файдалану өчен аны җайлаштыру эшләрен башкарганда«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкярләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән мәдәни мирас объектларын саклау буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты ;

Рөхсәт дубликатын бирү өчен:

Гариза;

Гариза бирүченең шәхесен яки вәкаләтләрен раслаучы документлар.

Документлар бер нөсхәдә бирелә.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);

почта аша.

Гариза һәм документлар, шулай ук, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә гариза бирүче тарафыннан Региональ портал аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин»

2.15 пункттагы «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты таләпләре исеме» баганасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләрдән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) , җирле үзидарә органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, яки алу мөмкинлеге булмау, мөрәҗәгать итүче теләге белән (экстерриториаль принцип), Федераль законның 15,1статьясында каралганча, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос (комплекслы запрос) бирү юлы белән»

2.15 пункттагы "Стандарт таләпләре эчтәлеге" баганасыняңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

Башкарма комитет бинасының (төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге) җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;

тиешле белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, "Интернет» челтәрендәге http://novosheshminsk.tatarstan.ru мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башкалар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдаланырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм итү.

Түбәндә саналган очраклар муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын билгели:

мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларга документларны тапшырганда чират булмау;

муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу очрагы булмау;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булмау;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр булмау.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченеңбер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Аралашуның дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://novosheshminsk.tatarstan.ru" сайтында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Бердәм порталында, КФҮтә алынырга мөмкин

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша муниципаль хезмәт күрсәтү, КФҮнең читтәге эш урыннары аша башкарылмый.

Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы соратып алу составында муниципаль хезмәт күрсәтелми»

2.16 пунктындагы «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты таләпләре исеме» баганасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Башка таләпләр, шул исәптән экстеррориаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча башкарылган булса) һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре»

2.16 пункттагы "Стандартның таләбенең эчтәлеге" баганасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша алырга мөмкин.

Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә гариза бирүче хокуклы:

а) Брдәм порталда яки Региональ порталда урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) Региональ порталның «Шәхси кабинеты» н кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гариза бирергә.

Региональ порталның «Шәхси кабинет»ы аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар җибәргәндә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куллланыла. Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 25.06.2012 ел, № 634 карарында каралган очракларда гади электрон имза кулланырга хокуклы;

в) электрон формада бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Региональ  портал аша муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә.;

д)  муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) бүлекнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) , шулай ук аның вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль районның рәсми сайты, төбәк порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять бирү процессын тәэмин итә торган шикаять бирергә.»

3 бүлектәге «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән

административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре» 3.3 пункт. «Гаризаны кабул итү һәм теркәү»:

3.3.1.пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат яисә КФҮ аша, КФҮнең ерактан торып эш урыны аша, муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача яки электрон формада гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Бүлеккә тапшыра.

Гаризаны электрон формада кабул иткәндә, Бүлекнең гаризаларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заты:

а) гаризаны электрон документ әйләнеше системасында теркәүне тәэмин итә, шул ук вакытта гаризага «Ведомство тарафыннан кабул ителгән» яки «Эшкәртүдә» статуслары бирелә, бу исә Региональ порталның «Шәхси кабинетында» чагылыш таба;

б) электрон култамганың чынбарлык шартларын үтәүне Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән тикшерә (мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган очракта).

Көчәйтелгән квалификацияле электрон култамганы тикшерү нәтиҗәсендә аның чынбарлыгы шартларын үтәмәү ачыкланмаса, бүлекнең вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза кергән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча, гаризаның теркәү номерын үз эченә алган, гариза алу датасын, файлларның исемнәрен, аңа тапшырылган документлар исемлеген, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасын күрсәткән гариза керү турында белдерүне җибәрә.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон култамганы тикшерү нәтиҗәсендә аның чынбарлыгы шартларын үтәмәү ачыкланса, бүлекнең вазыйфаи заты:

электрон формада кергән документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә;

мөрәҗәгать итүчегә «Электрон култамга турында» 06.04.2011 ел, № 63-ФЗ Федераль законның 11 статьясы пунктларын күрсәтеп, электрон рәвештә кабул ителгән карар турында хәбәрнамәне җибәрә. Мондый хәбәрнамәгә Бүлекнең вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела, электрон документлар әйләнеше системасында теркәлә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 25.08.2012 ел, № 852 карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне алу өчен мөрәҗәгать иткәндә көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгадан файдалану кагыйдәләренең 9 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән җибәрелә.»

3.5.3. пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитет җитәкчесе рөхсәт проектын яки нигезле рәвештә баш тартуны раслый һәм Теркәү бүлегенә җибәрә.

3.5.2 һәм 3.5.3 пунктлары белән билгеләнә торган процедуралар сорауларга җаваплар кергән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче нәтиҗәне электрон рәвештә алу ысулын сайлаганда мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен электрон документ формасында җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган рөхсәт яки теркәлүгә җибәрелгән мотивлаштырылган баш тарту.»

2. Әлеге карарны "Интернет"мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" нда (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**Җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**